**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
АЙБАШ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422726, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Айбаш авылы, Үзәк ур.,1А

**СОВЕТ АЙБАШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422726, Республика Татарстан, Высокогорский район
с. Айбаш, ул.Центральная, 1А

Тел./факс: +7(84365) 60-7-23, e-mail: Ayb.Vsg@tatar.ru

**КАРАР** **РЕШЕНИЕ**
**12 сентябрь 2023 ел** **№ 68**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Айбаш авыл җирлеге Советының "Физик затлар милкенә салым турында" 2015 елның 15 октябрендәге 13 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге, «Россия Федерациясе Салым кодексының икенче өлешенә үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 29 сентябрендәге 321-ФЗ номерлы Федераль закон, «Салым салу объектларының кадастр бәясеннән чыгып, физик затлар милкенә салым буенча салым базасын билгеләү тәртибен Татарстан Республикасы территориясендә куллануны башлауның бердәм датасын билгеләү турында» 2014 елның 30 октябрендәге 82-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Айбаш авыл җирлеге Советы

**КАРАР БИРӘ:**

1. Биектау муниципаль районы Айбаш авыл җирлеге Советының «Физик затлар милкенә салым турында» 15.10.2015 ел, № 13 карарына (Советның 26.04.2018 ел, № 113, 17.08.2018 ел, № 125, 28.11.2018 ел, № 140, 30.11.2022 ел, № 51 карары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә::

дүртенче абзацта 1 пунктчада 2 пунктта “бирелгән” һәм “дачный” сүзләрен бетерергә;

2 пунктның 1 пунктчасында өченче абзацны бетерергә;

3.1 пунктта өченче абзацны алып ташларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының интернет челтәрендәге http://vysokaya-gora.tatarstan.ru адресы буенча урнашкан рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан (халыкка чыгарылган) көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Совет Рәисе,
Авыл җирлеге башлыгы Р.Р. Сафиуллин